ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

01.11.2025 — Иннополис шәһәре — 90

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 13.08.2021 ел № 89 карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә «Татарстан Республикасының икътисад, социаль өлкә, дәүләт һәм муниципаль идарә тармакларының алга китешле ИТ-карарлары»региональ проектын гамәлгә ашыру кысаларында инженерлык челтәрләрен вектор форматында цифрлаштыру проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, шулай ук «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел № 210-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 13.08.2021 ел № 89 карары белән расланган Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.7 пунктча өстәргә:

«1.7. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.»;

1.2. Регламентның 2.5.2 пунктында түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) җир эшләренең чикләрен (полигонны) mif/mid форматында атрибутив мәгълүматтан башка яисә җир эшләрен җитештерүнең урыны турындагы белешмәләрне түбәндәге ысулларның берсе белән тулыландыру:

- МСК 16 системасында җир эшләренең урыны контурының характерлы нокталары координаталары;
- җир эшләре башкарыла торган территориядәге җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- эш урынының картографик яисә топографик нигездәге чикләре схемасы.»;

1.3. Регламентның 2.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендәге җир эшләре чикләре (полигоны) яки җир эшләре башкарылган урын турында түбәндәге ысулларның берсе белән белешмәләр:

- МСК 16 системасында җир эшләренең урыны контурының характерлы нокталары координаталары;
- җир эшләре башкарыла торган территориядәге җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- эш урынының картографик яисә топографик нигездәге чикләре схемасы.»;

1.4. Регламентның 2.5.5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына башкару төшерүендә күрсәтелә торган таләпләрне раслау турында» 16.09.2025 ел, №1308/о боерыгында бәян ителгән һәм җир эшләре чикләрендә төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслеге һәм тулылыгы мәсьәләсенә ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә векторлы форматта мск-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында векторлы модель структурасына туры китереп тутырылган семантика белән башкару төшерү.»;

1.5. Регламентның 2.5.6 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына башкару төшерүендә күрсәтелә торган таләпләрне раслау турында» 16.09.2025 ел, №1308/о боерыгында бәян ителгән һәм җир эшләре чикләрендә төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслеге һәм тулылыгы мәсьәләсенә ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә векторлы форматта мск-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында векторлы модель структурасына туры китереп тутырылган семантика белән башкару төшерү.»;

1.6. Регламентның 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) мөрәҗәгать итүче регламентның 2.6.1–2.6.6 пунктлары нигезендә үзе тапшырырга тиеш булган документларны тапшырмау яки каршылыклы белешмәләр булган яисә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документларны тапшыру»

1.7. Регламентның 3.5.2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җир эшләрен җитештерүгә ордерны ябу турындагы карар «Татарстан Республикасы пространстволы планлаштыру институты» ДБУ белән һичшиксез килештерелергә тиеш.;

1.8. 3.3.3.1, 3.4.4, 3.5.2.1, 3.5.2.2 һәм 3.5.3. пунктларында «электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә» фразасын «ГИСОГД системасы ярдәмендә» фразасына алыштырырга;

1.9. Регламентка 1 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.10. Регламентка 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.11. Регламентка 3 нче кушымталарны, әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.12. Регламентка 12 нче кушымталарны, әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.13. Регламентны, әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә, 14 нче кушымта белән тулыландырырга;

1.14. Регламентка әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә 15 нче кушымта өстәргә;

1.15. Регламентка, әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә, 16 нчы кушымта өстәргә;

1.16. Регламентка әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә 17 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча: http://verhniy-uslon.tatarstan.ru һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында халыкка игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы А.А. Баһавиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Хуззятов

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
1 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
1 нче кушымта

Тышкы төзекләндерү элементларын вату-җимерү белән бәйле
җир эшләрен башкаруга
№ ________ОРДЕР

«__» ________.20__ ел

Заказ бирүче: ___________________________________________________________

Эшләр җитештерүче:

___________________________________________________________

Адрес һәм подрядчы телефоны:

____________________________________________________

Адрес һәм субподрядчы телефоны:

______________________________________________

Җир эшләрен җитештерү рөхсәт ителә _______________________________________

Яклар җитештерә торган эшләр адресы: _______________________________________

___________________________________________________________________________

Эшләр башкару тәртибе һәм ысулы:

___________________________________________________________________________

Яшел зонада эшләргә таләпләр:

Бозу белән: мәйданы _ кв. м булган юл өслеге, асфальт өслеге - _ кв. м, газон - _ _кв. м.

Җир эшләрен башкару рөхсәт ителә«___» _____20__ елдан «___» _______20__елга кадәр
Төзекләндерү һәм тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле җир эшләрен башкаруга ордерны «___» _____20__елга кадәр ябу

Җитәкче _____________

Ордерга кушымта
җаваплы зат (прораб, мастерлар) тарафыннан тутырыла.

Мин, ____________________________________________________________,
(Ф.И.А.и, вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

эшләр башкарыла башларга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакырырга, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу кагыйдәләре нигезендә башкарырга, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәргә һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкарырга вәгъдә бирәм. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тотарга әзер.

Эшләр җитештергәндә төп таләпләр турында белешмә белән таныштым.

Эшләр җитештерүче ____________________________________________________________
(Ф.И.А.и, вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

«__» __________ 202_ ел

**Белешмә**

1. Эшләр башланганчы җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрне башкару башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмага хәбәр итә. Заказчик (төзүче) подрядчикны җитештерүгә ордер рәсмиләштерергә хокуклы.

2. Бозылган юл капламаларын, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3. Утыру һәм деформацияләр килеп чыкканда объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен эксплуатациягә кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланганнан соң өч көн эчендә объектны тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң төзекләндерүне торгызу буенча эшләрне кабул итү акты белән тапшыра, аңа «АТИ» МКУ вәкиле һәм заказчы вәкиле кул куя.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы койма белән әйләндереп алынырга тиеш, участок «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Административ – техник инспекциясе» МКУ белән килештерелгән проект белән билгеләнгән чикләрдә урнашырга тиеш.

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына керү һәм торак биналарга керү

юллары буш булырга, траншеялар аша күчеш күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар материаллар төрләре буенча штабдәнәләргә салынырга һәм траншеяләрдәге җир белән кушылмаска һәм урам хәрәкәтенә комачауларга тиеш түгел. Кире күмү өчен яраксыз булган траншеяләрдән грунтны эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр һәм чокырлар 0,2 м калынлыктагы комлы грунт белән күмелергә, җентекләп тыгызланырга һәм су сибелергә тиеш (җәй көне). Кыш көне траншеяларны һәм чокырларны тыгызлап эрегән комлы грунт белән күмәргә кирәк.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

Эшләр җитештерүче ______________________________

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
2 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
2 нче кушымта

Тышкы төзекләндерү элементларының бозылуына бәйле
авария-торгызу эшләрен җитештерүгә
№ ________ОРДЕР

«__» ________.20__ ел

Заказ бирүче: ____________________________________________
(юридик затлар өчен оешма исеме, ИНН/ физик затлар өчен мөрәҗәгать итүченең ФИА.и.)

Эшләр җитештерүче:

_______________________________________________________
(оешма исеме, җаваплы затның ФИОА.и., телефон)

Эш төре:

_____________________________________________________________

Челтәрләр атамасы:

______________________________________________________

Эшләр җитештерүнең адресы:

____________________________________________________________________

________________________________________ нигезендә,

«_____» _____________ 20___ел № ___
_________________________________________белән килештерелгән

«___»_____20__ елдан «___»_______20__ елга кадәр җир эшләрен башкару, шул исәптән бозылган төзекләндерү эшләрен төгәлләү рөхсәт ителә.

Эшләрне башкару тәртибе һәм ысулы:

____________________________________________________________

____________________________________________________________________

Яшел зонада эшләргә таләпләр:

Бозу белән: мәйданы _ кв. м булган юл өслеге, асфальт өслеге - _ кв. м, газон - _ _кв. м.

Җитәкче ______________

Ордер билгеләнгән срок дәвамында гамәлдә.
Эшләр җитештерүне ордерны тулысынча рәсмиләштергәннән соң гына башкарырга

Ордерга кушымта
җаваплы зат (прораб, мастерлар) тарафыннан тутырыла.

Мин, ____________________________________________________,
(Ф.И.А.и, вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

эшләр башкарыла башларга өч көн кала, эшләр зонасында урнашкан инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешма вәкилләрен урынга чакырырга, эшне СНиП һәм җир асты челтәрләрен проектлау һәм салу кагыйдәләре нигезендә башкарырга, югарыда күрсәтелгән барлык шартларны үтәргә һәм эшне ордерда билгеләнгән срокта башкарырга вәгъдә бирәм. Әлеге ордер буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тотарга әзер.

Эшләр җитештергәндә төп таләпләр турында белешмә белән таныштым.

Эшләр җитештерүче ______________________________________________
(Ф.И.А.и, вазыйфасы, җаваплы затның эш урыны)

«__» __________ 202_ ел

Белешмә

1. Эшләр башланганчы җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерә, эшләрне башкару башлануы турында объектны карап тотуны һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмага хәбәр итә. Заказчик (төзүче) подрядчикны җитештерүгә ордер рәсмиләштерергә хокуклы.

2. Бозылган юл капламаларын, яшел утыртмаларны һәм төзекләндерүнең башка элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

3.Утыру һәм деформацияләр килеп чыкканда объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен эксплуатациягә кайтару турындагы актка имза салынган көннән алып билгеләнгән срок эчендә торгызу эшләрен башкаруның гарантияле срогын тәэмин итә.

4. Ордерда күрсәтелгән эшләр срогы тәмамланганнан соң өч көн эчендә объектны тышкы төзекләндерү элементларын бозуга бәйле эшләрне башкарганнан соң төзекләндерүне торгызу буенча эшләрне кабул итү акты белән тапшыра, аңа «АТИ» МКУ вәкиле һәм заказчы вәкиле кул куя.

5. Казу урыны билгеләнгән типтагы койма белән әйләндереп алынырга тиеш, участок «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Административ – техник инспекциясе» МКУ белән килештерелгән проект белән билгеләнгән чикләрдә урнашырга тиеш.

6. Җир эшләре башкарылган барлык очракларда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеге тәэмин ителергә, ишегалларына керү һәм торак биналарга керү юллары буш булырга, траншеялар аша күчеш күперләре урнаштырылырга тиеш.

7. Юл өслеген сүтеп ташлаудан калган материаллар материаллар төрләре буенча штабдәнәләргә салынырга һәм траншеяләрдәге җир белән кушылмаска һәм урам хәрәкәтенә комачауларга тиеш түгел. Кире күмү өчен яраксыз булган траншеяләрдән грунтны эш барышында чыгарырга кирәк.

8. Юлларда һәм тротуарларда траншеяләр һәм чокырлар 0,2 м калынлыктагы комлы грунт белән күмелергә, җентекләп тыгызланырга һәм су сибелергә тиеш (җәй көне). Кыш көне траншеяларны һәм чокырларны тыгызлап эрегән комлы грунт белән күмәргә кирәк.

9. Җир асты челтәрләрен салу кагыйдәләрен, ордер һәм кисәтү кәгазе шартларын бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

Эшләр җитештерүче ______________________________

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
3 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
3 нче кушымта

Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирүдә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

______________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

№ ________ гаризасы "___" _____________ 202_ ел,

___________________________________________________________________________
турында

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, моңа бәйле рәвештә:

1. ___________________________________________________________________________

2. ___________________________________________________________________________

Җитәкчесе ______________________

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
4 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
12 нче кушымта
.

Туфрак эшләре алып бару өчен ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

__________________________________________________мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

___________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

№____ гариза «___» ________ 202 ___ ел,

_______________________________________________________________________________
турында

_______________________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде,бу уңайдан:

1. _____________________________________________________________________________

2. _____________________________________________________________________________

Җитәкче ______________________

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
5 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
14 нче кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу срогын озайту турында
№ ________ БЕЛДЕРҮ

____________________________________________________мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

______________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

«___» __________ 202 ___ ел ______ № гариза,

________________________________________________________________________________
___ турында

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ордерның гамәлдә булу вакытын озайту турында «___» _______ 202___ № _______ карар кабул ителде

Җитәкче ________________________

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
6 нчы кушымта
.
Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
15 нче кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында
№ ________ БЕЛДЕРҮ

__________________________________________________ мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

__________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

«___» _________ 202 ____ ел № _____ гариза

__________________________________________________________________________
турында

__________________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында «___» _________ 202 ____ел № _______ карар кабул ителде

Җитәкче __________

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
7 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
16 нчы кушымта

Җир эшләрен башкару ордерына тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу
эшләренең гамәлдә булу срогын үзгәртү турында белешмәләрне һәм
башкару турында белешмәләрне кертү хакында
№ ________ БЕЛДЕРҮ

№________ _____._____.________ ел
(кышкы чорда)

__________________________________________________мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

___________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

җир эшләрен башкару ордерына тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләренең гамәлдә булу срогын үзгәртү турында белешмәләрне һәм башкару турында белешмәләрне кертү хакында «___» _______ 202 ____ ел № _______ гариза

гаризаны карау нәтиҗәләре буенча җир эшләрен җитештерүгә ордерның гамәлдә булу срогын 202 ______ ел «___» _______ кадәр үзгәртү турында карар кабул ителде.

Тышкы төзекләндерүне өлешчә торгызу эшләрен башкаруга кагылышлы белешмәләргә үзгәрешләр кертергә, атап әйткәндә:

_____________________________________________________________________________

Җитәкче ______________

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2025 елның «01» ноябреннән
№90 карарына
8 нче кушымта

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2021 елның «13» августыннан
№ 89 карарына
17 нче кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында муниципаль хезмәт күрсәтүдән
баш тарту хакында
КАРАР № _____

____________________________________________________мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә

______________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының
исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

гариза № ______ "______" ______________ 202 __ ел
________________________________________________________________________ турында

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, моңа бәйле рәвештә:
________________________________________________________________________________

Җитәкче ________________________